МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ
И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ
БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань / Казан ш. **БОЕРЫК**

12.03.2026 223-п

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Бөгелмә Зәй елгасы, Мошкара елгасы, Акташка елгасы, Ямашка елгасы, Морат елгасы, Зәй сусаклагычы, Бөгелмә елгасы, Кудаш елгасы, Мактаминка елгасы, Нариман елгасы, Урсалинка елгасының су саклау зоналарын һәм яр буендагы саклау полосаларын билгеләү, һәм Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматларга үзгәрешләр кертү турында

Рәсәй Федерациясе Су кодексының 65 статьясы, “Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында” 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 32 статьясы, Рәсәй Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 31 октябрендәге карары белән расланган Су саклау зоналары чикләрен һәм су объектларының яр буе яклау полосалары чикләрен билгеләү Кагыйдәләре нигезендә № 1459, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре” 06.07.2005 ел, № 325 карары белән һәм 27.06.2025 ел, № 2025.008 контракт кысаларында башкарылган эшләр йомгаклары буенча “Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Дала Зәе елгасы кушылдыкларының: Бөгелмә Зәе елгасы, Мошкара елгасы, Акташка елгасы, Ямашка елгасы, Морат елгасы, Зәй сусаклагычы, Бөгелмә елгасы, Кудаш елгасы, Мактаминка елгасы, Нариман елгасы, Урсалинка елгасы (II этап) яр сызыклары (су объектлары чикләре) урнашу урынын билгеләү турында” боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларының су саклау зоналарының һәм яр буе яклау полосаларының киңлеген, әлеге чикләрдә хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыруның махсус режимын исәпкә алып, Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясы нигезендә билгеләргә:

1.1. Бөгелмә Зәе елгасы
су саклау зонасының киңлеге - 200 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 40 м.

1.2. Мошкара елгасы
су саклау зонасының киңлеге - 100 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 50 м.
1.3. Акташ елгасы
су саклау зонасының киңлеге - 100 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 50 м.
1.4. Ямашка елгасы
су саклау зонасының киңлеге - 100 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 50 м.
1.5. Морат елгасы
су саклау зонасының киңлеге - 100 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 50 м.
1.6. Зәй сусаклагычы
су саклау зонасының киңлеге - 200 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 40 м.
1.7. Бөгелмә елгасы
су саклау зонасының киңлеге - 100 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 50 м.
1.8. Кудаш елгасы
су саклау зонасының киңлеге - 100 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 50 м.
1.9. Мактаминка елгасы
су саклау зонасының киңлеге - 100 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 50 м.
1.10. Нариман елгасы
су саклау зонасының киңлеге - 100 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 50 м.
1.11. Урсалы елгасы
су саклау зонасының киңлеге - 100 м;
яр буе яклау полосасының киңлеге - 50 м.

2. Су объектларын саклау бүлегенә (А.Р. Гыйззәтуллина) Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Бөгелмә Зәй, Мошкара, Акташ, Ямашка, Морат, Зәй сусаклагычы, Бөгелмә, Кудаш, Мактаминка, Нариман, Урсалинка елгаларының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе яклау полосалары чикләре турында белешмәләр җибәрергә:

2.1 билгеләнгән тәртиптә дәүләт су реестрына кертү өчен су ресурсларының федераль агентлыгына;

2.2 территорияләренә карата су саклау зоналары һәм яр буе яклау полосалары чикләре билгеләнә торган муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына;

2.3 Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә (аның территориаль органы) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрындагы белешмәләргә үзгәрешләр кертү өчен.

3. Экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендә проектларны пропагандалау бүлегенә (Е.В. Веселова) әлеге боерыкны татарчага тәрҗемә итәргә.

4. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (Р.А. Заһидуллин) әлеге боерыкны теркәү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары О. В. Мандичевага йөкләргә.

Министр А.И. Җиһаншин